ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СӘФӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423748, Иске Сәфәр авылы,
М.Вахитов ур., 16 нчы йорт.
Тел.5-60-43

СОВЕТ СТАРОСАФАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423748, село Старое Сафарово,
ул. М.Вахитова ,дом 16 , Тел. 5-60-43

КАРАР
от 21.11.2019 г.

РЕШЕНИЕ
№ 28

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 7 августындагы 45-ТРЗ номерлы татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Иске Сәфәр авыл җирлеге гражданнары җыены

Карар:

1. Иске Сәфәр авыл җирлеге территориясендә 2020 нче елда, ,, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлардан тыш, бер тапкыр түләүләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Иске Сәфәр, Иске Кадырмәт, Терпельдә урам юлларын ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм вак таш салу, грейдлау, кардан чистарту);
- Иске Сәфәр авылында Терпеле елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау
Җирлек чикләрендә Халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:
- Иске Сәфәр, Иске Кадырмәт, Терпеледә скважиналарны лицензияләү, су челтәрләрен карап тоту һәм алыштыру;;
Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру
- Иске Кадырмәт һәм Терпеле авылларындагы һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү ; ;
Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
-- зират коймасын ремонтлау; зират коймаларын буяу өчен лак-буяу материаллары сатып алу;
- җирлек территориясендә агач кисү;
Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру:
- җирлек территориясендәге хуҗасыз объектларны һәм йортларны сүтү;
- урамнарны яктырту электр челтәрләрен урнаштыру, тоту;

- торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;

2. Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге гражданнарының авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында җыелу нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Иске Сәфәр авыл җирлеге башлыгы Г.З.Сайфутдинова